**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 10 2022 ел Яр Чаллы № 3026

Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, Башкарма комитетның «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

- 2.5 пункт: Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләрнең тулы исемлеген, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибен тулыландырырга һәм түбәндге редакциядә бәян итәргә:

2.5.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен, мөрәҗәгать итү категориясенә һәм нигезенә карамастан, түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затларның законлы вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

3) гариза:

- документ формасында кәгазьдә (әлеге Регламентка 4 кушымта);

- Регламентның 2.5.4 пункты таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла), Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

4) ата-ана никахта торса яисә никахта тормаса, әмма бергә яшәгәндә, икенче ата-ананың паспорты;

5) бала тууны Россия Федерациясеннән читтә теркәгән очракта, чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык һәм аның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе;

6) ундүрт яшькә җиткән баланың паспорты (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

7) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карары, бала туу турында таныклыкта уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш;

8) милектә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлеге бирелгән очракта, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар;

9) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

10) җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү хакында суд карары (гариза бирүче паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында билге булмаган очракта);

- 2.6 пункт: Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалар карамагында булган, шулай ук мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе, әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма - тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) күчемсез милек объектына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

2) яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;

3) никах теркәү (өзү) турында белешмәләр - Россия Федераль салым хезмәте;

4) үлемне дәүләт теркәве турында белешмәләр - Россия Федераль салым хезмәте;

5) тууны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүмат - Россия Федераль салым хезмәте;

6) мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган докумен, законлы вәкил гариза бирү очрагында (Россия Федерациясе Граждан хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) - Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры яисә Бердәм дәүләт социаль тәэминат мәгълүмат системасы;

7) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, аларга милеккә түләүсез җир кишәрлекләре бирелгән (тапшырылган) гражданнар реестрыннан белешмәләр - Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;

8) паспортның чынбарлыгы турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;

9) фамилия-исем төркеме, туу датасы, җенес һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү - Россия Федерациясе пенсия фонды;

10) ышанычнамәне бирү факты һәм эчтәлеге турында белешмәләр - бердәм нотариат мәгълүмат системасы;

11) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

12) җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү хакында суд карары (гариза бирүче паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында билге булмаган очракта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин